**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**К А Р А Р**

«18»март 2022 ел          Иштирәк авылы          № 19/1

«Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 июлендәге 37/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше һәм 5 статьясы 1.3 өлеше, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. «Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 июлендәге 37/3 номерлы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен район Башкарма комитетына тапшыру турында мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү объектларына концессион килешү төзүгә уртак конкурс үткәрүне оештыру;
- муниципаль милекне арендага бирү һәм милекче кушуы буенча концессиягә тапшыруны оештыру.

2. Әлеге карарны Иштирәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында ((https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https:// (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы          Г.С. Гарифуллина